КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 май г.Казань № 320

«Түбән Кама агросәнәгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе исемен үзгәртү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Түбән Кама агросәнәгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесен «Түбән Кама транспорт инфраструктурасы көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенә үзгәртү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә «Түбән Кама агросәнәгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. «Түбән Кама транспорт инфраструктурасы көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе тарафыннан дәүләт биремен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) һәм дәүләт заданиесен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә дәүләт биремен формалаштыру тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, бу карарның 2 пунктын үтәгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасының кайбер норматив хокукый актларын бу карарның 1 пунктына туры китерү өлешендә әлеге актларга үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин